РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«УРМАНАЕВСКОЕ СЕЛЬСКОЕ
ПОСЕЛЕНИЕ» АЗНАКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«УРМАНАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

ул. Татарстан д.15«а», с.Урманаево,
Азнакаевский район, 423311

Татарстан урамы, йорт 15 "а", Урманай авылы
Азнакай районы, 423311

Тел./факс(8-85592)4-30-49/4-31-56; E-mail Azn.Urman@tatar.ru; http://aznakayevo.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 19 » октябрь 2023ел № 03

2024 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлеге Беренче Май торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрү турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлеге Уставынын 15.1 статьясы нигезендә, карар итәм:

1.Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлегенең Беренче Май бистәсе торак пунктында теркәлгән Верхняя урамы буенча 01 йорттан 33 йортка кадәр, Средняя урамы буенча 01 йорттан 12 йортка кадәр, Нижняя урамы буенча 01 йорттан 35 йортка кадәр теркәлгән, сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2024 елда үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын 2023 елның 02 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлегенең Беренче Май бистәсе торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы – Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлеге башкарма комитеты;

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Сез, 2024 елда Урманай авыл җирлеге Беренче Май торак пункты территориясендә беренче төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан гаилә әгъзасы мобилизацияләнгән гаиләләр һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт үтү турында контракт төзегән гражданнар тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Халыкны су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын ремонтлау (су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау һәм тоту, килешү буенча эш өчен түләү, материаллар, җиһазлар, материаллар сатып алу, авария хәлләрен бетерү, торбаларны алыштыру);

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын ремонтлау, тоту (Верхняя, Средняя, Нижняя урамнары буенча вак ташлар салу, тракторчыга механикалаштырылган кар җыю буенча хезмәтләр өчен түләү, торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге юлларны тоту буенча чит оешмалар хезмәтләре өчен түләү, килешү буенча эшләр өчен түләү);

**«РИЗА»** **«КАРШЫ».**

5. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Урманай авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

6. Әлеге карар халыкка җиткерелгән көннән үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымнан калдырам.

Башлык: Э.Р.Абдуллина